

«Призыв» гәжитендә Ләмберә районы халкынын матур эшләре турында кvп языла. Чираттагысы социаль контракт турында.
Тырышкан табар, ташка кадак кагар, ди халкыбыз. Ләмберәдә яшәvче Альмира Абдулхак кызы Биктяковага, vз эшен башлап жибәргәндәге авырлыкларны жинәргә социаль контракт ярдәм иткән. Анын кибете жирле халык очен сәvдә ноктасыннан зуррак мәгънәдә, чонки бирегә килгән якташлары бер-берсе белән аралаша, тәжрибә уртаклаша һәм сонгы яналыклар белән таныша. «Ой янындагы кибет» тә шулай булырга да тиеш.
Кибет хужасы Альмира Абдулхак кызынын хыялын тормышка ашырырга социаль контракт булыша. - Мин егерме елга якын Мәскәvдә эшләдем, - ди Альмира ханым Биктякова. – Анда бvгенге конгә кадәр яшәр һәм эшләр идем, әмма мәсьәлә кабыргасы белән торды - әнигә даими кайгырту кирәк булды. Ана инде 85 яшь һәм минем ярдәмемнән башка ул тормышын дәвам итәлмәячәк. Мәскәvдә эштән китәргә һәм туган якларына кайтырга туры килде.
Туган жиргә кайткач, язма героебызга эш эзләргә туры килә. Торле вариантлар була, әмма Ләмберә Большевистская урамындагы коммерция ноктасы ачу ин унайлыларыннан: буш кибет бинасыннан әнисе йортына кадәр – ике адым юл; шәхси тәжрибә һәм бухгалтерлык белеме бизнес очен бик яхшы момкинлек. Барысын башлап жибәрv очен эш «кечкенәдә» торган - акча кирәк булган.
- Мин барлык вариантларны башымнан уздырдым: акчам житми. Жиһазлар жыя алыр идем, ләкин аренда һәм товар сатып алу очен тvли алмас идем. Кредит алырга уйладым. Тик сәvдә ноктамда нинди финанс әйләнеше булырга момкинлеген кvз алдыма китердем. Нәтижәдә, сәvдәнен барлык акчалары кредитны тvләvгә китәр иде.
Ләмберә соцзащитасына бардым. Ышандым да, барысы да килеп чыгар дип ышанмадым да. Чынлыкта, бу ботенләй жинел эш тvгел. Документларны жыярга, заявканы дорес рәсмиләштерергә кирәк иде. Бу эштә «Мордовиянын Ләмберә районы буенча халыкны социаль яклау» хезмәткәрләре ярдәм итте, әмма топ эшне мостәкыйль башкарырга туры килде. 2022 елнын мартына социаль контрактка гариза рәсмиләштерелде. Май аенда акча керде. Берәрсе очен 250 мен сум аз кебек тоелса да, мина берничә жиһаз (киштәле витрина, касса аппараты) сатып алырга, арендага һәм беренче товарны сатып алуга да житте. Минем хыялым тормышка ашты - кибетемне ачтым, ди.
Белгәнебезчә, кvп әкияттәге теләк vтәлешендә бетә. Ләкин без әкияттә тvгел. Сәvдә ноктасы эшли башлаган, сатып алучылар булган һәм проблемалар да vзләрен озак коттереп тормаган. Шул вакыт Абдулхак кызы Альмира барлыкка килгән мәсьәләләрне чишә алуына шикләнмәгән, чонки ул vз клиентларын яхшы белә. Урам зур булса да, урта яшьтәге кешеләр иртә белән эшкә китәләр һәм еш кына ойгә кайтышлый зур кибет хезмәтеннән файдаланалар. Анын сатып алучылары - олкән яшьтәге кешеләр һәм балалар, шунын турында бизнес планында язган да инде:
- Мин шунда ук әбиләремә товарнын очызлысын, пенсиядән сатып алырга булганын китердем һәм хаталандым: пенсионерларыбыз арзанны алмыйлар, икән. Хәзер vзем

кулланган товарны гына йортәм.
Кибет ассортиментын сатып алучылар теләгенә карап янарта эшмәкәребез. «Йорт янындагы» сәүдә ноктасы очен стандарт азык-толек жыелмасы: икмәк, сот һәм сот продуктлары, колбаса һәм жиләк-жимеш, ниндидер матур пакетлардагы вак-тояк. Хәзер сатучы нинди икмәк һәм кvпме тәкъдим итәргә, нинди тундырма йортергә, кvпме балык сатып алырга икәнен белә. Барысы да яхшы сыйфатлы булырга тиеш. Мәсәлән, икмәкнен Починковскиен гына алалар. Башкаларын да сатарга тырышкан, әмма икмәкнен яртысын кире кайтарырга туры килгән. Өйе, товардан тагын да моһим деталь - аралашу. Олкән яшьтәге сатып алучылар кибеткә товар артыннан гына тvгел, ә аралашу очен дә килә. Кемдер моны авыл белән аралашу гадәте дип атар, без бизнес-стратегиянен «клиент белән шәхси эш» дип аталган олеше буларак карый Альмира Абдулхак кызы. Шулай кон артыннан кон vтә: кибет, сатып алучылар, товар сатып алу, йорт, йокы һәм тагын янадан... Шимбә конне Абдулхак кызы Альмираны кызы алыштыра.
- Кайчагында еларга хәлем житә: эшлим, тырышам, ә исәпләсәм – акча кулда калмый диярлек, ди әнгәмәдәшебез. - Безгә бигрәк тә январь ае салкыннары жәберлек китерде. Кибетне жылыту тәvлек буе максимумда эшләде. Монын очен кvпме акча китәчәген әле санамадым да.
Һәм, әлбәттә, конкуренция зур икәнен беләбез. Зур сәvдә челтәрләре һәм бай кибетләр сатып алучыларны vз әсирлегенә алырга ондәп торалар. Шуна кvрә Альмира Абдулхак кызы очен мактау буларак «...ни очен без сумкаларны ерактан тартып китерәбез икән, синен кибетендә дә бар икән» янгырый. Без хәзерге шартларда бизнес алып бару кыенлыкларын тасвирлыйбыз, кемнедер куркыту очен тvгел. Үз эше турында хыялланган һәм социаль контрактка морәжәгать иткән һәркем әкият булмаячагын анлавы моһим. Сезгә балык тvгел, ә кармагы бирелә. Калганнарынын барысы да авыр хезмәтегезгә бәйле. Әмма язма героебыз:
- Минем эшем vсә: теләгәнемчә тиз тvгел, ләкин ул vсә. Кайчак авыр булса да, кибетемне ташламаячакмын һәм бизнестан баш тартмаячакмын. Артка юл юк, димәк, алга барырга гына туры киләчәк. Анда бик кvп кыенлыклар һәм киртәләр, жинел булмаган даими хезмәт булачак. Уныш та булачак, - ди vз эшенен хужасы.
Альмира Абдулхак кызы Биктякова бvген нәкъ менә шул хакта хыяллана һәм кибетенен исеме булуын тели: «Момкинлекләр булгач, мин матур билге заказ бирәчәкмен һәм кибетемне оныгым исеме белән атыячакмын».

**Наилә НАСЫРОВА әзерләде**